

Катлаулы эпидемиологик хәл һәм vз-vзенне изоляцияләv чорында Мордовия халкы, ойдән чыкмыйча гына, торле хезмәтләр очен тvләvләрне ешрак башкара. Тvләvне мобиль почта-касса терминаллары белән жиһазландырылган хат ташучылар кабул итә.

Россия почтасы, covid-19 шартларында максималь санда кешеләр сәламәт калсын очен, кулдан килгәннен барысын да эшли. Кешеләр ойдән азрак чыга торган саен, аларнын сәламәтлегенә куркынычы да тvбәнрәк булачак. Бигрәк тә сәламәтлекләре белән проблемалары булган олкән яшьтәге кешеләргә һәм vз-vзенне изоляциялəvне сакларга кирәк кешеләргә. Республика халкы кирәкле почта хезмәтләрен ала алсын очен, Россия Почтасы ойдә берничә сервис тәкъдим итә, шул исәптән, мобиль почта-касса терминаллары ярдәмендә, почтальоннар тарафыннан тvләvләрне кабул итv дә.
Мордовия почтальоннары коммуналь хезмәтләр, элемтә, интернет хезмәтләре, иминият полисларын рәсмиләштерv, шулай ук ГИБДД штрафларын кvчермә жайланмалар ярдәмендә кабул итте. Транзакцияләр vсеше 2020 елнын апреленә 65%тан артык тәшкил итте.
Коронавирус йогышы таралу куркынычы Мордовия халкын мәжбvри тvләvләрне башкару тәртибен яна дан карарга мәж бvр итте. «Если раньше услуга по приему платежей почтальонами на дому была востребована пожилыми и маломобильными людьми, то сегодня почтальонов приглашают все, кто хочет минимизировать контакты с окружающим миром. Приход почтальона, оснащенного мобильным терминалом, а также средствами защиты – маской и перчатками дает возможность сохранить собственную безопасность”, -  дип билгеләп vтте Мордовия Республикасы УФПС директоры Вячеслав Макейчев.
Коммуналь һәм башка тор тvләvләр очен почтальоннын пенсия яки корреспонденция вакытында килеп, яки аны якындагы почта бvлекчәсеннән телефон аша чакырганда тvләргә момкин.
Мәгълvмати белешмә. Мордовия Республикасы УФПС “Россия Почтасы” 12 почтамптны, автобазаны, 489 почта элемтәсе бvлеген vз эченә ала, шуларнын 420се – авылныкы. Филиалларда 2 500 кеше эшли, шул исәптән 1070 почтальон.

*Марина ЧЕЛАК*